# Халык авыз иҗаты

Халык авыз иҗаты әсәрләре:

1.Бишек җырлары
2.Такмаклар
3.Такмазалар
4.Санамышлар
5.Табышмаклар
6.Мәкальләр
7.Әкиятләр
8.Мәсәлләр
9.Тизәйткечләр
10.Мәзәкләр




http://edu-teacherzv.ucoz.ru

Кайбер әкиятләрнең,табышмак, җыр, такмак, санамыш, мәзәк, бишек җырларының авторы бер генә кеше түгел, ә бик күп кешеләр була. Андый әсәрләрне халык иҗаты диләр. Бу әсәрләр бик борынгы чорлардан ук телдән телгә күчеп килгән, шуңа күрә аларны **халык авыз иҗаты** дип тә йөртәләр.

http://edu-teacherzv.ucoz.ru

Мәкаль – халыкның тормыш тәҗрибәсен туплаган кыска, тирән мәгънәле төгәл җөмләләр ул.


Мәкальнең төп мәгънәсе “сөйләп,әйтеп бирү”дигәнне аңлата.Төп максаты – фикер әйтү.



## Мәкальләр

Тән биргән дә ана,
Сөт биргән дә ана,
Тел биргән дә ана,
Көй биргән дә ана.

Ата –анаң чын дустың,
Дус – ишләрең юлдашың.



**Бишек** -яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланып эшләнгән асылмалы ятак яки йоклату урыны.





Бишек җыры - бишектәге баланы тирбәтеп йоклатканда, юатканда җырлана торган җыр.



# Бишек җыры.

Әлли – бәлли бәүкәем,
Җан йөрәгем, нәнкәем,
Рәхәт кенә тынычлап
Йоклап китәр бәбкәем...



## Бишек җырлары.

Әлли – бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу.
Бәү – бәү итеп,күз йомып
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп
Үсеп буйга җитәр бу,
Абыйлары артыннан
Мәктәпләргә китәр бу.
Мәктәпләрдә укыгач,
Галим булып җитәр бу.





Тел шомарткычлар – авазларны дөрес әйтер өчен кулланыла торган шигъри әсәрләр.

Карамага карама

- Карама, карама,карамага карама,
- Карамага карасаң, ике күзең карала.

( карама – ясень)



Такмаклар – бию өчен яки күңел ачу өчен әйтелә торган халык иҗаты әсәрләре.

Бие,бие,бие әле,
Биегәнең юк әле;
Сине матур бии диләр,
Биетеп карыйк әле.
Челтәр икән якасы,
Бигрәк матур тәңкәсе;
Аккош микән,былбыл микән
Моны үстергән әнкәсе.






Санамышлар – кайбер уенны башлап җибәргәндә балалар арасында әйтелә торган үзенә бер төр тезем сүзләр.



## Санамыш.

### Кура җиләк

Бер  чиләк, ике чиләк,
Өч чиләк, дүрт чиләк,
Биш чиләк,алты чиләк,
Җиде чиләк,сигез чиләк,
Тугыз чиләк – кура җиләк!




Табышмак – зиһен ачкычы

Төп мәгънәсен уйлап белергә кирәк булган нәфис сүзне табышмак диләр.



Җире ак,
Орлыгы кара,
Кул белән чәчәләр,
Авыз белән җыялар.



Агач түгел – яфраклы,
Күлмәк түгел – тегелгән,
Кеше түгел – сөйли,
Нәрсә ул?






# Мәзәк – күңел ачкычы

## Саф һавада йөри

- Алсу, нигә дәресеңне әзерләмәдең?
- Ут юк иде.
- Ә телевизор карадыңмы соң?
- Аны бит мин караңгыда карадым.

